Алга, белем иленә!

# Мәктәбем минем

**Казан шәһәре Идел буе районының 78 нче урта гомуми белем мәктәбе укучыларының нәфис басмасы**

**1 нче ноябрь, 2014 нче ел**

**№1**

Мәктәбем,
Без килгәч бүгеннән
Күңелле булачак.
Сыйныфлар моннан соң
Гел гөрләп торачак.
Без сине үзебез
Сагындык өзелеп,
Менә бит кошлар күк
Килдек без тезелеп.



## Әлеге санда:



**Тарих сәхифәләре ( 2нче бит)**



**Сәламәт тәндә– сәламәт акыл**
**( 3 нче бит)**



**Илһам канатында ( 4 нче бит)**



Беренче сентябрь – минем
Бәхет-шатлыклы көнем
Сагынып белем учагын,
Мин кабат сиңа килдем
Дулкынланып карап торам
Юксындырдың, мәктәбем,
Син – минем үткән гомерем,
Син – минем киләчәгем.

Синдә күрергә өйрәндем
Матурлыгын дөньяның
Тәүге кат синдә башкардым
Балачагым җырларын
Мәңге исебездә тотыйк
Монда үткән чакларны
Алган белемебез белән
Бизик туган якларны.

# Тарих сәхифәләрендә

**Дәрдемәнд, чын исеме Закир Рәмиев — XX гасыр башының бөек татар шагыйре, җәмәгать эшлеклесе.**

1859 елның 23 ноябрендә Ырынбур губернасы Эстәрлетамак өязендәге (хәзерге Башкортостанның Мәләвез районы) Жиргән авылында туа. 1862 елның җәендә әтисе, гаиләсен алып, Орск өязенең Юлык авылына күчеп китә. Закирне һәм аның абыйсын башта өйдә укыталар. Аннары Муллакай авылындагы мәдрәсәгә бирәләр. Закир 1880-1881 елларда Истанбулда яши, төрек телен, әдәбиятын өйрәнә.

1890-1900 елларда бертуганнар Шакир белән Закирга аталарыннан Орск өязендәге алтын ятмалары күчә. Алардан 1917 елга кадәр барлыгы 5 тонна алтын табыла. Рәмиевләр прискларның техник җиһазландыруын кайгырткannar. Приискларда барлыгы 850 эшче көч куйган. Рәмиевләрнең иганәчелек эше шактый мәгълүм. Алынган табышка алар татар язучыларының әсәрләрен бастырганнар, уннарча мәктәпләр тотканнар, татар студентларына матди ярдәм күрсәткәннәр, мәчетләр төзегәннәр. Алтын ятмаларын арендага биреп торган башкортларның авылларында үз хисапларына мәчетләр төзегәннәр, мәдрәсәләр ачканнар.



***Татар әдәбияты классигы Дәрдемәнднең (Закир Рәмиевның) тууына 155 ел. ( 1959-1921)***

1905 елдан Шакир белән Закир Рәмиевләр Оренбургта матбугат чыгару эшен башлыйлар. 1906 елда «Вакыт» гәзите (башта атнасына өч тапкыр, аннары көн дә чыга башлый), 1908 елдан «Шура» журналын чыгара башлыйлар («Вакыт»ның мөхәррире Фатих Кәрими, "Шура"ныкы Риза Фәхретдин була). Бу ике басма да 1918 елда ябыла.

Октябрь инкыйлабыннан соң типографиясен, алтын прискаларын яңа хакимияткә тапшыра. З.Рәмиевның шәхси китапханәсен әрәм итеп, яндырып бетерәләр.

1921 елгы ачлык вакытында халыкка ярдәм итү эшен оештыруга керешә, ләкин авырып китә һәм шул елның 9 октябрендә вафат була.

**Материалны 7 нче Г сыйныфы укучысы Ильвина Садреева әзерләде**

# Сәламәт тәндә — сәламәт акыл! 3 нче бит

### Барлык милләтләрнең йөгерү көне

21 нче сентябрь көнне без Казан Арена мәйданы янында үткәреләчәк чарага җыелдык.





Монда Казан шәһәренең төрле мәктәпләреннән балалар, уку йортларыннан студентлар һәм гаиләләр дә килгәннәр иде. Эстафетаны иң элек гаиләле кешеләрдән башладылар. Аларны карап тору үзе кызык булды. Әтиләр үзләренең кечкенә балаларын кулларына күтәреп йөгерәләр. Кайбер гаиләләр төркемләшеп йөгереп үтәләр. Менә инде безнең чират та җитте. Йөрәкләр әллә нишләп китте. «Беренче булып килсәм, шәп булыр иде дә, булдыра алмам шул”-дигән уй башка килеп китте. Янымда озын буйлы, көчле яшьтәшләрем тора. Менә сигнал бирелде, киттек. Чабам, чабам, тыным бетә башлады. Әкрен генә финишка да якынлаштым.

Әлеге көн күңелле үтте. Киләчәккә дә мая туплап, спорт белән шөгыльләнергә кирәклеген аңладым.

**7 нче М сыйныфы укучысы**
**Ләйлә Магеррамова**

**Матурлык- сәламәтлек билгесе.**
**Байлык бер айлык, саулык- гомерлек.**
**Сәламәт булуның бер юлы- хәрәкәт итү.**
**Бурычын яшергән бөлгән, авыруын яшергән үлгән.**
**Таза булсаң, таш та ярып була.**
**Баш сау булмаса, мал күзгә күренми.**
**Гыйлемнән яхшы дус юк, чирдән яман дошман юк.**
**Саулык - зур байлык.**





## Һөнәр сайлау җиңел эш түгел

Кечкенәдән инде без үзебезнең киләчәк һөнәребез турында сөйләшә башлыйбыз. Кечкенә балалар иң кызыклы, төрле һөнәрләрне сайлый башлыйлар. “Үскәч кем буласың килә?” дигән сорауга бик җитез җавап бирәләр. Кемдер очучы булырга тели, кемдер космонавт, ә кемдер табиб, укытучы, хәтта пешекче буласы килә, дип җавап бирәләр.

Ә менә минем бу сорауга еллар үткән саен җавапларым үзгәрә бара. Мин бик күп төрле һөнәрләр беләм, тик иң ошаганы укытучы һөнәре. Минемчә, укытучы булу авыр һәм җаваплы, шул ук вакытта кызыклы да.

Еллар уза бара. Артыбызда күңелле мәктәп еллары үтеп бара һәм гомер безне яңа юлга алып чыга. Нинди булачак безнең киләчәк юлыбыз? Нинди һөнәрне сайларга? Инде хәзер без үзебезнең киләчәк һөнәребез турында уйлана башлыйбыз, ләкин сайларга бик авыр шул.

Хәзерге вакытта кирәкле, төрле һөнәрләр күп. Елдан – ел югары уку йортлары арта бара: институтлар, университетлар, академияләр тәҗрибәле белгечләрне әзерләп чыгаралар. Әлбәттә, һәр кешенең һөнәре кызыксындырырлык, ә кеше үзенең һөнәренә сәләтле булырга тиеш.

Бездә беренче сәләтне ачучы ул безнең укытучыларыбыз. Нәкъ беренче укытучыбыз бездә бүтән кеше күрмәгән сәләтне күрә. Ул безгә үзебезнең юлыбызны сайларга булыша.

Быел мин 10 нчы сыйныфны тәмамлыйм. Мин югары уку йортына керергә әзерләнәм. Иң кызыклы, мөһим һөнәр, минем уйлавымча, ул - полиция һөнәре. Мин сайлаган һөнәр элек тә, хәзерге вакытта бик кирәкле булып саналган. Бу һөнәрне сайларга миңа гаиләм булышты. Полиция җәмәгатьчелек тәртибен тәэмин итү, иминлек белән шөгыльләнә. Полиция һөнәре берничә төргә бүленә. Мин тикшерүчеләр бүлеген сайладым, чөнки ул, куркыныч булса да, киң таралган, халыкка бик файдалы, дөреслекне яклаучылар бүлеге.

Полиция һөнәре мине үзенең авырлыгы белән бер дә куркытмый, чөнки бу һөнәрне сайлыйм икән, мин инде анда эшләячәгемне беләм.Үземдә рухи ныклык барын мин сизәм. Иң әһәмиятлесе – курыкмыйча, үзеңә куйган бурычыңны үтәргә кирәк. Үзеңә ошаган һөнәрне сайласаң гына синә тормышта җиңел булачак.

Һәр яшь кешегә, ошаган һөнәрен сайлап, тормышыннан тәм һәм ямь табып яшәргә язсын иде. Халыкта “Эшчән бәхетне эшендә күрер, ялкау бәхетне төшендә күрер” дигән мәкаль бар бит. Халык әйтсә, хак әйтә.

**10 нчы Б сыйныфы укучысы**
**Гүзәл Камалеева**



## Әти-әниемнең яраткан һөнәрләре

... Иң мөкатдәс нәрсә эш.
Эш агачы һәрвакытта
Бик юмарт китерер җимеш.
Габдулла Тукай.

Мин кечкенә чагымнан ук әнием белән идән юган, әтием эштән кайтканчы дип, ашарга пешерешкән, савыт-саба юган чакларны хәтерлим. Бу эшләрне мин хәзер әти-әнием өйдә югында үзем генә дә башкарам. Кечкенәдән өйрәнгәч, бер дә авыр түгел икән. Ә әнием, миңа рәхмәт әйтеп, эшеннән кайтып керә.

Минем әнием Гөлнара исемле.Ул Балтач районы Нормабаш авылында туып үскән. Шунда урта белем, хезмәт тәрбиясе алган. Әле дә әнием авылга кайткач, йорт тирәсендә йөгереп эшләп кенә тора. Әнием, Казанга килеп, педагогия училищесында укый, тәрбияче һөнәрен сайлый. Ул балаларны бик ярата, балалар бакчасындагы кечкенәләр дә аны бик якын итәләр. Әнием балалар бакчасына көн саен шатланып бара. Ул алар белән төрле уеннар уйный; аларга әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр сөйли; белем бирә; аларны чисталыкка-пөхтәлеккә өйрәтә. Кечкенәләргә матур итеп эндәшүе, киң күңелле булуы, җырга-биюгә осталыгы - әниемне бизи торган сыйфатлар. Мондый сыйфатлар чын тәрбиячедә булырга тиеш дип уйлыйм. Тәрбияче һөнәрен сайлаганына әнием бер дә үкенми. Ул үз эшенә бик җитди карый. Тормышта мин әниемнән үрнәк алам. Ул үз балаларына да, чит кеше балаларына да яхшы тәрбия бирергә тырыша. Ә мин тәрбияче һөнәрен яратып башкарган кеше киләчәккә яхшы күңелле буын тәрбияли ала дип беләм.

Минем әтием дә халкыбызга бик файдалы, күңеленә шатлык, рәхәтлек бирә торган һөнәр сайлаган. Аның исеме – Динар. Ул Биектау районы Киндери авылында туып үскән. Авыл җирен яраткангадыр, аның машина йөртүче булып эшләве дә шәһәр белән авыл арасын бәйләп тора. Ул машина белән районнардан шәһәргә сөт ташый. Әтием, иртән иртүк торып, яраткан машинасына утыра да юлга кузгала. Ә без аңа “Хәерле юллар” теләп калабыз, әтиебезнең исән-сау эшләп кайтуын көтәбез. Машина йөртүче булу юлларда бик игътибарлылык сорый. Әтием, өйдә тәртипле кеше булганга, юлларда да җайлап кына йөри, үз эшендә мактаулы кеше булып санала. Юлларда йөрү авыр булса да, әтием үз эшен бик яратып башкара, чөнки ул халкыбызга хезмәт итә.

Шулай итеп, минем әти-әнием бик кирәкле һәм файдалы һөнәрләр сайлаганнар, тормышыбызда үз урыннарын тапканнар. Алар үзләренең эшләре белән хезмәттәшләре арасында хөрмәтле кешеләр. Үз һөнәрләрен яратып башкарган кеше генә тирә-якка ямь өсти ала дип беләм мин.

**8 нче Г сыйныфы укучысы**
**Айгөл Мәрданова**

# Илһам канатында

### Тәмле җәй

Аланнарда – җиләк исе,
Басуларда – иген исе,
Җәйләүләрдә – сөт исе…
Тагын аллы-гөлле чәчәк,
Кайнар кояш өстисе –
Шушы булыр җәй төсе!

**Ш.Галиев**

### Җәй көнендә

Каты эссе. һава бөркү. Кыза дөнья, сабыр җитми,
Җил исми аз гына да, бер генә яфракны селкетми.

Корылык һәр урыннарда. Кибә вак-вак кына күлләр,
Шиңәргә йөз тота кырда үләннәр, чәчкәләр, гөлләр.

Агачлар астына сыгъна балалар барчасы бергә,
Алай да булмаса, барсы төшәләр сикрешеп күлгә.

Алар ап-ак балыклар күк йөзәләр иртәдән кичкә
Кадәр шунда, туңып бетмичә ярга чыкмыйлар һич тә.

**Г.Тукай**

***Җәй бик матур ел фасылы. Аның үтеп киткәнен сизми дә каласың. Әйе, шушы җиләкле, чәчәкле, күңелле вакытларны кем генә искә алмас.***

### Җәйге яллар

**Менә каникуллар да үтеп китте. Уку вакыты да килеп җитте.**

**Мин җәйнең беренче айларында сеңелем белән авылда булдым. Волгоград шәһәреннән энем кайтты. Без аның белән балык тотарга бардык. Җәйнең эссе көннәрендә су да коендык. Әби белән бабайга да булыштык: бакчага су сиптек, чүп утадык, печән җыйдык.**

**Җәй уртасында без Казанга кайттык. Кырлай паркында, зоопаркта булдык.**

**Август аенда без гаиләбез белән Болгар шәһәренә дә барып кайттык. Анда бик матур Ак мәчет һәм музейлар бар. Музейларның берсендә мин дөньядагы иң зур изге китапны— Коръәнне күреп кайттым. Әлеге китап асылташлар, көмеш һәм алтыннар белән бизәлгән иде. Әлеге сәяхәттән мин дусларыма сувенирлар да алып кайттым.**

**Менә шулай итеп җәй дә үтеп китте. Ә инде кем Болгар шәһәрендә булмаган, барырга тәкъдим итәр идем.**

**7 нче М сыйныфы укучысы**
**Илназ Салахов**

### Җәй

**Минем быелгы җәем бик күңелле үтте. Без гаилә белән кайларда гына булмадык. Башта без дәү әнигә һәм дәү әтигә кунакка кайттык. Аларның бакчаларында яшелчәләр, җиләк-җимешләр үстерергә булыштык. Җәйнең эссе көннәрендә рәхәтләнеп су коендык. Зәй елгасы буена төшеп, балык тоттык.**

**Мин дәү әбием белән дару үләннәрен дә җыярга яратам. Бу истәлекле һәм күңелле көннәре дә хәтеремнән чыкмый.**

**Казанга кайткач, без Кырлай паркына да бардык.**

**Җәйнең могзиҗалы, рәхәт көннәрен әле дә сагынам. Тагын да зур хыяллар белән киләсе җәйне көтеп калам.**

**7 нче М сыйныфы укучысы**

**Гөлназ Мотыгуллина**



# Илһам канатында



***Бу елларны ничек онытасы***
***Ил язмышы кылыч йөзендә,***
***Ир-егетләр китте яу кырына***
***Алып көче тоеп үзендә.***
***Ирләр китте, кызлар елап калды,***
***Туйда кигән күлмәкләре калды,***
***Күпме бала калды, ятимнәр.***
***Шаулап калды иген өлгереп.***
***Басу капкасына чаклы озата барды***
***Яше-карты барсы өзелеп.***
***Ирләр китте, кызлар елап калды,***
***Елап калды күпме хатыннар.***

## *Тиздән Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтәчәкбез*

**Дога булсын**

Олы РӘХМӘТ, РӘХМӘТ сезгә,
Әй, газиз ветераннар!
Якты дөнья бүләк безгә
Сездән, чын каһарманнар.
Каршылагыз бу бәйрәмне
Әле йөз һәм мең кабат!
Ничек кайтарыйк рәхмәтне?
Ни гамәл кылыйк савап?
Нинди генә эш кылсаң да,
Аз булырдыр шул, дуслар.
Хәтердә тот һәрвакытта,
Иң мөһиме – игътибар.
Күңел тула, яшь ялтырый –
Якын Җиңү бәйрәме.
Әллә ничек, кул калтырый,
Җыям чәчәк бәйләме.
Озын гомер теләсен
Бу чәчәкләрем минем.
Дога булып ирешсен
Саклаучыларга илен!

**7 нче М сыйныфы укучысы**
**Гөлназ Мотыгуллина**

**Ант итәм**

Бабайлардан ишетеп,
Беләбез сугыш хәлләрен.
Күп кешеләр баш салганын,
Күздән яшьләр тамганын.

Яшь кызларның егетләрен
Сугышка озатканнарын,
Көтәргә дип вәгъдәләшеп,
Озатып калганнарын.

Хатлар аша өзгәләнеп
Сөю аңлашуларын,
Югалту хәбәре алып,
Кайгыда калуларын.

Батыр егет баш имичә,
Соңгы сулышка чаклы
Вәгъдәсенә тугры калып.
Сугышта башын салды.

Батырлыгы алдында
Башыбызны иябез.
Онытмаска сүз бирәбез
Сез, Батырлар, диябез!

**7 нче Г сыйныфы укучысы**
**Алсу Әхмәдуллина**

# Мәктәп хәбәрләре



*Көз көннәре килеп җитте,*
*Хушлашабыз җәй белән.*
*Бөтен җиргә яфраклардан*
*Алтын келәм җәелгән.*

**Бик күңелле бакчада -**
**Алтын сары бар дөнья!**
**Җил яфраклар биетә,**
**Көз шатлана, туй итә.**

## Көзге муллык

Әкрен генә табигатькә көз дә аяк басты. Нинди матурлык, нинди хозурлык! Кая карама, бөтен җирдә сары, алтын төстә яфраклар ята. Үзеңне әкияти бер дөньяда йөргән кебек хис итәсең.

Көз – ул җәйнең нәтиҗәсе дә булып тора. Нәкь менә бу вакытны җәен эшләпме, әллә ялкауланып ял итеп кенә үткәрелгәне күренә. Көз көне зур уңыш җыеп керсәң, кышны рәхәттә үткәрерсең. Вареньеларны, тозлы кыяр, помидорларны, дару үләннәрен көзгә хәтле әзерләп бетергә кирәк.

Юкка гына халык: “Чебешләрне көзен саныйлар” дип әйтмәгәндер. Быелгы уңышны күрер өчен, мәктәптә “Көзге уңыш” исемле күргәзмә оештырылды. Өстәлләр тулы, мул иде.

Һәр килгән көз шулай мул уңышы белән безне сөендереп торсын иде.



**7 нче М сыйныфы укучысы**
**Эльвина Гибадуллина**

**Җирдә сары яфраклар –**
**Көз килүнең билгесе.**
**Сары яфрак көз чибәрнең**
**Төшеп калаган көзгесе.**



## Сайлаулар! Килми калмагыз!

14 нче сентябрь — сайлаулар көне иде. Әлеге көн якшәмбегә туры килсә дә, мәктәбебез гөрләп эшләде. Сайлауга килгән һәр кеше хәйрия өстәленнән балаларның үз куллары белән ясаган әйберләрен сатып ала алды. Шулай ук тәмле, кайнар чәй эчәргә теләүчеләргә дә бу көнне ашханә ачык иде. Төрле сыйныф укучылары концерт номерлары күрсәтеп, килгән кунакларның күңелләрен күтәреп тордылар.

**7 нче Г сыйныфы укучысы**
**Алсу Әхмәдуллина**



### Укытудагы яңалыклар

**Ике көн буена мәктәптә яңа педагогик технологияләрне өйрәнү буенча укытучылар өчен курслар булып узды. Әлеге укулардан һәр кеше үзе өчен яңалык алмый калмагандыр. Күп кенә нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр булдык. Замана алга барган саен, укыту системасы да яңарып торырга, нәтиҗәлерәк булырга тиеш. Хәзерге көндә укучыларыбыз алдына мәгълүматны эзли, таба һәм эшкәртә белү бурычы куела .**

**Әлеге курсларның уңай яклары:**

- **коллективны бердәм булырга өйрәтә;**
- **кешене төрле яклап ача;**
- **тыңларга һәм икенче кешене хөрмәт итәргә өйрәтә;**
- **төрле проектлар өстендә эшне булдыра;**
- **фантазияне үстерә;**
- **теория белән практиканы бәйли.**



# Эш беткәч, уйнарга ярый

## Табышмак әйтәм, җавабын тап!

Үзем дә ап – ак,
Эзем дә ап – ак.
Белем бирәм дип
Сызылам кат – кат.
(Акбур)

Агуын да, угын да
Үзе белән йөртә ул.
Ачуы килгәннәргә
Икесен дә кертә ул.
(Бал корты)

Сызгычыңны сызып җибәр –
Көйләр агылсын әле.
Йөрәкләргә мин чыгарган
Моңнар кагылсын әле.
Телгәләсен бәгырьләрне,
Актарылсын уйлары.
Башларыңны кыңгыр салып,
Кылларымда уйнале.
(Скрипка)

Чулпан да ул, Зөһрә дә,
Венера да кайчакта.
Шундый матур балкып
тора
Кояш уянган чакта.
(Йолдыз)

Бертуктамый йөзәбез,
Йә төшәбез кар булып.
Йә төшәбез яңгыр булып,
Ә исемебез ...
(Болыт)

# Котлыйбыз!




### Кадерле әниләр!

Сезне якынлашып килүче Әниләр бәйрәме белән тәбрик итәбез.

Сез – безнең яклаучыбыз, саклаучыбыз, барыр юлыбызны яктыртып торучы мәңге сүрелмәс кояшыбыз. Сез булган җирдә ризык бар, җан җылысы бар.

Бердәнбер иң кадерле, иң хөрмәтле, иң якын кешеләребез - Әниләр!

Балаларыгыз турында гел яхшы сүзләр генә ишетеп яшәргә язсын Сезгә! Без бит беләбез: әниләр өчен моңардан да зуррак бәхет юк!

Матур булсын, котлы булсын бәйрәмегез!



**Мөхәррирләр:** А. Әхмәдуллина, Г.Батталова, С. Семенова, И.Садреева, Э. Гибадуллина, И.Салахов, Р. Идрисов, А. Мәрданова.
**Консультант:** Л.И. Исмаилова

*Мәктәбем минем*

**Безнең адресыбыз:** ТР Казан шәһәре Идел буе районы 78 нче урта белем бирү мәктәбе (Ю. Фучик урамы, 40 нчы йорт), 420139 тел./ факс: 268– 58-61
E– mail: https://edu.tatar.ru/priv/school78
**Газетабызны түбәндәге сайттан күрергә мөмкин:**
https://edu.tatar.ru/priv/school78/page813169.htm
**Хатларыгызны түбәндәге адреска юллагыз:**
lyutsiya_906@mail.ru